ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

12 май 2023ел № 3878

Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия турында нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4570 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Яр Чаллы шәһәре территориясендә сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия турында нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2020 елның 14 сентябрендәге 4570 номерлы карарына (Башкарма комитетның 2021 елның 7 декабрендәге 7934 номерлы карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 нче кушымтада:

- 4 пунктта «Татарстан Республикасы Президенты» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисе» сүзләренә алмаштырырга;

- 25 пунктта:

1 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) ягулык-энергетика комплексы һәм сәнәгать производствосы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча;»;

4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) транспорт өлкәсе, идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча.»;

- 27 пунктта 9, 10, 11, 12 пунктчаларны төшереп калдырырга;

- 30 пунктка түбәндәге эчтәлектәге 5, 6, 7, 8 пунктчалар өстәргә:

«5) транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларны фаразлауны һәм планлаштыруны;

6) транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру буенча чараларның нәтиҗәлелеген анализлауны;

7) транспорт чараларының һәм транспорт объектларының һәм корылмаларының (тимер юл станцияләренең һәм юлларының, ремонт предприятиеләренең, күперләрнең) ихтимал булган югалтуларын һәм җимерелүләрен билгеләүне;

8) транспорт системасы эшчәнлегенең тотрыклылыгын алга таба арттыру буенча тәкъдимнәр әзерләүне.»;

2) 2 нче кушымтаны кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2023 елның 12 маендагы
3878 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 14 сентябрендәге
4570 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре территориясендә
сугыш вакытында һәм гадәттән тыш хәлләрдә
оешмаларның тотрыклы эшләвен арттыру буенча комиссия
составы

| №<br>т/б | Ф.И.А.и. | Вазыйфа |
|---|---|---|
| 1. | Зуев Илья<br>Сергеевич | комиссия рәисе, Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары |
| 2. | Устимов<br>Руслан Семенович | комиссия рәисе урынбасары, ТР буенча Россия ГТХМ Баш идарәсе Күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эшләр идарәсенең Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| 3. | Матросов<br>Рәмзи Таһир улы | комиссия секретаре, Татарстан Республикасы ГТХМ Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге буенча идарәсе башлыгы урынбасары (килешү буенча) |
| | | комиссия әгъзалары: |
| 4. | Гыйләҗева<br>Гүзәл Вәлиәхмәт кызы | ягулык-энергетика комплексы һәм сәнәгать производствосы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе, Башкарма комитетның икътисадый үсеш һәм эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү идарәсе башлыгы |
| 5. | Кондрабаева<br>Әлфия Ринат кызы | торак-коммуналь хуҗалыгы эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы |
| 6. | Парамонов<br>Максим Геннадьевич | транспорт өлкәсе, идарә, элемтә һәм хәбәр итү системалары эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе, Башкарма комитетның шәһәр хуҗалыгы һәм халык яшәешен тәэмин итү идарәсе башлыгы урынбасары, транспорт һәм элемтә бүлеге башлыгы |
| 7. | Хәлимов<br>Рамил Мәрван улы | социаль өлкә эшчәнлегенең тотрыклылыгын арттыру төркеме җитәкчесе, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева